Программа рецензирована
научным сотрудником кафедры татарского языка и литературы
ГАОУ ДПО «Институт развития образования Республики Татарстан»
доцентом, кандидатом филологических наук
Л. Г. Гилязовой (5 февраля 2024г.)

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
3 нче гимназия муниципаль белем бирү учреждениесе

# «Аралашу этикеты»

5-11 нче сыйныф укучылары өчен
дәрестән тыш эшчәнлек буенча авторлык программасы

Автор: Фәтхетдинова Рузилә Ринат кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Чистай – 2024

## Аңлатма язуы

Мәктәпне тәмамлаган һәр укучы тормышка яраклашкан булырга һәм җәмгыятьтә кешеләр арасында аралашу нечкәлекләренә дә төшенергә тиеш. Гадәттә, мәктәп укучысы эшлекле аралашу кагыйдәләрен белми һәм аудитория алдында чыгыш ясарга әзерлексез була, югалып кала, эшлекле аралашуның телдән һәм язма формаларын төзи алмый, чөнки мәктәптә моңа махсус өйрәтмиләр. Иртәме-соңмы укучы аралашу этикетын үзләштерергә мәҗбүр була, теге яки бу ситуациядә үз-үзен ничек тотарга кирәклеге турында уйлана.

Сөйләм, аралашу осталыгы һәрбер һөнәр вәкиле өчен мөһим. Кызганычка каршы, хәзерге көндә сөйләм осталыгына өйрәтү өчен дәресләрдә бирелгән вакыт кына җитми. Хәтта телевидениедә эшләүче кайбер алып баручыларның да хаталы сөйләмен, басым кую кагыйдәләре, авазлар орфоэпиясе бозылышын ишетеп борчылабыз. Бүгенге көндә бу актуаль проблема, шуңа күрә бу түгәрәкнең эшчәнлеге мөһим дип саныйм. Бирелгән түгәрәк программасы укучыга тормышта тәүге тапкыр һәм аннан соңгы адымнарны ясаганда килеп туган каршылыкларны җиңәргә ярдәм итү, ялгышлардан кисәтү, аралашу культурасын үзләштерү максаты белән төзелде. "Сөйләм осталыгы" түгәрәге балаларны халкыбызның рухи-әхлакый идеалларына китерергә, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтен үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерергә тиеш. Түгәрәктә танып-белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла.

Укучылар түгәрәктә татар теле һәм әдәбиятыннан, рус теле һәм әдәбиятыннан алган белем һәм күнекмәләрен файдаланалар, тел чараларын камилләштерәләр, рус-татар грамматикасын чагыштырма планда җөмләләр төзеп өйрәнәләр, эшлекле аралашу этикетын махсус кагыйдә-тезислар аша үзләштерәләр, эшлекле уен, диалог, әңгәмә, язма һәм сөйләм текстлары формалаштыру рәвешендә тормышка ашыралар. Түгәрәк дәресләрендә татар теле, әдәбияты, рәсем, җыр сәнгате, уеннар һәм сәхнә әсәрләре бәйләнештә бирелә.

Түгәрәк занятиеләрен лекция, практикум, проект эше яклау, очрашу-әңгәмә, экскурсия, кичә һ.б. формаларда үткәрергә мөмкин. Программа атнага 1 дәрес исәбеннән төзелде, барлыгы – 34 сәгать. Түгәрәктә 5-11 нче сыйныф укучылары шөгыльләнә ала.

**Максат:**

- Укучыларга сөйләм әдәбенең нәтиҗәле алымнарын, аралашу үзенчәлекләрен, аралашу этикетын аңлату;
- Сөйләмнең телдән һәм язмача формалары белән таныштыру,укучыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү;
- Укучыларда аралашу культурасы тәрбияләү.

**Бурычлар:**

- Ораторлык сәнгате үзенчәлекләрен күрсәтү;
- Татарча-русча эшлекле этикет формаларын бирү;
- Аралашканда үз-үзеңне тоту, позитив һәм негатив фикер агышының тәэсирен сурәтләү;
- Лидерлык үзенчәлекләрен ачу;
- Образлы сөйләм, тавыш хәрәкәте, жестлар һәм мимиканың роле турында мәгълүмат бирү;
- Аудиторияне яулап алу серләренә төшендерү;
- Төрле милләт, төрле ил кешеләренең аралашу үзенчәлекләрен күрсәтү;
- Рухи тормыш нигезләрен аңлату.

**Түгәрәкнең юнәлеше, көтелгән нәтиҗәләр:**

- Укучыларны традицияләребезгә нигезләнгән үзара аралашу культурасына өйрәтү;
- Теоретик һәм практик белемнәрне үзләштереп, аралашу этикетының иң мөһим кагыйдәләрен тормышта иркен куллана белүләренә ирешү;
- Балаларның сөйләм телен баету; эстетик зәвыгын, иҗади фантазияләрен үстерү;
- Төрле даирә кешеләре белән аралаша алу, тормыш тудырган авырлыклар алдында югалып калмау күнекмәләрен формалаштыру.

## ТҮГӘРӘК ЭШЕН ПЛАНЛАШТЫРУ

| № | Дәресләрнең темасы | Үткәрү формасы | Сәгать саны | |
|---|---|---|---|---|
| | | | теория | практика |
| 1 | Кереш. Сөйләм этикеты. Этика һәм этикет сүзләренә аңлатма бирү. | Лекция. Эшлекле уен (төркемнәрдә эш) | 1 | |
| 2-3 | Эффектлы аралашу һәм чыгыш ясау. Дулкынлану һәм каушауны җиңү. | Лекция, сөйләм формаларын чагыштыру. | 1 | 1 |
| 4 | Кыюлык һәм үз-үзеңә ышану. Эффектлы башлангыч. “Өч мәртәбә” кагыйдәсе. Эффектлы йомгаклау. | Текст төзү, практик эш. | 1 | 1 |
| 5-6 | Образлы сөйләм һәм дөрес сайланган тон, сулыш алу, интонация, тизлек, тавышның көче һәм пауза. | Эшлекле уен, ярыш, сөйләм формаларын чагыштыру | 1 | |
| 7-8 | Ораторлык сәнгате. Аудиторияне яулап алу. | Лекция, эшлекле ситуацияләр. Сәнгатьле уку бәйгесе | 1 | 1 |
| 9 | Жест һәм мимика. Гәүдәне хәрәкәтләндерү. Халыкара жестлар аңлатмасы. | Лекция, конспект, тезислар төзү | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10-11 | Сәхнәдә үз-үзеңне тота белү. Алып баручы. Сөйләмдә көлү-көлдерү максатында ирония, юмор-мәзәк чаралары куллану. Җор теллелек, ораторлык | Бәйрәмнәрдә чыгыш ясарга әзерлек, репетицияләр | 1 | 1 |
| 12 | Позитив һәм негатив хәрәкәтләр, сигналлар. | Тезислар төзү, чагыштырма ситуацияләрне күзәтү. | 1 | |
| 13-14 | Пассивлык һәм агрессивлык. Эффектлы аралашу күнекмәләре. | Текстлар анализлау, диалоглар төзү | 1 | 1 |
| 15 | Үз-үзеңә ышанганлык."Мин" алмашлыгы. Аудиторияне үзең белән тигез күрү – уңышлы чыгыш ясауның нигезе. | Эшлекле әңгәмә. Эшлекле үрнәк текстлар төзү. | 1 | |
| 16 | Эчке диалог. Үз-үзеңне тоту. | Эшлекле уен. Эзләнүләр һәм нәтиҗәләр. | 1 | |
| 17 | Психологик халәт. Ачулану һәм ярсуның көтелгән эшкә кире тәэсире. | Лекция, тезислар. | 1 | |
| 18-20 | Язма формада эшлекле аралашу. Активлык, төгәллек, кыскалык. | Документлар, эш кәгазьләре төзү. | 1 | 2 |
| 21-22 | Язма һәм телдән сөйләм формалары | Сөйләм үстерү күнегүләре, иҗади эшләр | 1 | 1 |
| 23 | Татарча-русча эшлекле этикет формалары. | Текстлар чагыштыру, эшлекле уен. | 1 | |
| 24-25 | Татар-рус телләренең грамматик нигезләре. | Сүзтезмәләр,җөмләләр төзү, аларны тәрҗемә итү һәм чагыштыру. | 1 | 1 |
| 26 | Риторика-чыгыш ясарга һәм аралашырга өйрәтүче фән | Риторика фәненең үзенчәлекләрен ачыклау, текстлар төзү | 1 | |
| 27-28 | Эшлекле аралашу этикеты. Танышу. Әңгәмә оештыру. | Эшлекле уен, конспект, тезислар төзү. | 1 | 1 |
| 29 | Рәсми эндәшү формалары | Кагыйдәләр үзләштерү, диалоглар төзү | 1 | |
| 30 | Бәхәсләшә белү осталыгы | Төрле очракларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, ситуатив күнегүләр | | 1 |
| 31-32 | Лидерлык сәләтен ачу. Лидерлык үзенчәлекләре. | Конспект төзү, текстлар өстендә эш. | 1 | 1 |
| 33 | Эмоциональ интеллект. Көчле эмоцияләрне җиңү. Бәхетле кешеләрнең сыйфатлары. Рухи тормыш нигезләре. | Тезислар төзү, риваять тыңлау һәм анализлау. | 1 | |
| 34 | Кешене тыңлый белү сәләте – олы сәнгать. Яхшы тыңлаучы булу серләре. Нәтиҗә ясау. | Лекция, тезислар төзү. | 1 | |

## Программаның эчтәлеге

**1 нче дәрес**. Укытучы кереш лекция сөйли, курсның максатларын һәм бурычларын аңлата, укучыларны эш тәртибе белән таныштыра, этика һәм этикет сүзләренә гомуми аңлатма бирә. Сәнгать халык байлыгы, ул аның тормышы кызыксынуларына бәйле. Сәнгать, әдәбият телдән башка үсә алмый, чөнки тел – аралашу чарасы, көрәш коралы.

**2-3 нче дәресләр**. Сөйләм (нәфис сүз) – эшлекле аралашу әдәбенең бер өлеше.Публика алдында чыгыш ясауның алшартлары китерелә. Дулкынлану һәм каушауны җиңү өчен укучылар бирелгән сөйләм формаларын чагыштыралар, нәтиҗәле форманы сайлап алырга өйрәнәләр.

**4 нче дәрес**. Узган дәреснең дәвамы буларак, бу дәрестә укучылар үзләре текст төзиләр. Укытучы чыгышны төгәл, анык, аңлаешлы һәм аудиториянең игътибарын яулап алырлык көчле интонация белән башлап китүнең эффектлы башлангыч булуын ассызыклый. Кереш, төп өлеш, йомгаклау өлешендә әйтергә теләгән фикерне өч мәртәбә кабатлауның тыңлаучыга нәтиҗәле тәэсирен күрсәтә, финал шулай ук чыгышның әһәмиятле өлеше икәнлеге искәртелә. Укучылар текст буенча өйрәнгәннәрне практикада кулланып карыйлар.

**5-6 нчы дәресләр**. Алдагы дәрестә өйрәнгәннәр дәвам итә. Укытучы дәрес темасы буенча аңлатмалар, күрсәтмәләр бирә, укучылар эшлекле уен башкаралар, сөйләм формаларын чагыштыру буенча ярыш үткәрелә.

**7-8 нче дәресләр**. Үтелгән дәресләргә йомгак ясала. Ораторлык сәнгате үзенчәлекләре кабатлана, искә төшерелә,дәфтәрләргә теркәлә, аудиторияне яулап алу серләре аңлатыла. Укучылар эшлекле ситуацияләр чишәләр, эзләнәләр. Сәнгатьле уку бәйгесе оештыру.

**9 нчы дәрес**. Укытучы чыгыш ясау барышындагы төрле тән хәрәкәтләре, гәүдә торышы, жест һәм мимикаларга аңлатма бирә. Халыкара жестларның нәрсә белдерүләрен өйрәтә. Укучылар лекция барышында конспект төзиләр, тезислар рәвешендә язып баралар, практикада бу хәрәкәтләрне кулланып аңлашалар.

**10-11 нче дәресләр.** Сәхнәдә үз-үзеңне тота белү кагыйдәләре белән таныштыру. Алып баручы ролендә уйнап карау. Сөйләмдә көлү-көлдерү максатында ирония, юмор-мәзәк чаралары кулланып төрле ситуатив күнегүләр чишү. Диктор яки алып баручы дөрес итеп сулыш ала белергә тиеш. Әгәрдә сөйләмнең теләсә кайсы урынында сулыш алынса, сөйләмебез аһәңле һәм яңгырашлы булмас иде. Сөйләмнең тыңлаучыга тәэсире, аның тизлеге, эмоциональлеге, тавышның югарылыгы, түбәнлеге. Нәфис сүз остасы чыгышы.

**12 нче дәрес**. Позитив һәм негатив сүзләренә аңлатма бирелә, позитив һәм негатив сигналлар сүзлеге китерелә, аларны укучылар дәфтәрләренә теркәп куялар. Мәсәлән, елмаю, ачык һәм ябык поза нәрсәне аңлата һ.б. Кыска әсәрләрне сәхнәләштерү.

**13-14 нче дәресләр**. Бу дәрес алдагы дәреснең дәвамы булып тора. Пассив һәм агрессив сүзләренә аңлатма бирелә, аларның аралашучыга һәм чыгыш ясаучыга тискәре тәэсире күрсәтелә. Эффектлы аралашу өчен кирәкле күнекмәләр ассызыклана, дәфтәрләргә теркәлә. Укучылар диалог төзеп сөйләшәләр.

**15 нче дәрес**. Үз-үзеңә ышанганлык тирә-юньдәгеләр, аудиториядәге тыңлаучылар белән үзеңне тигез күрүдән башлануы турында аңлатма бирелә. Укытучы чыгыш ясаучы фикеренең аудиториядә яклау тапмаган очраклары вакытында үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында киңәшләр бирә. “Сез” алмашлыгы урынына күбесенчә “без” һәм “мин” алмашлыклары куллануның нәтиҗәлерәк булуын искәртә, мисаллар, текстлар ярдәмендә ныгыта, анализлый, әңгәмә оештыра.

**16 нчы дәрес.** Эчке диалог сүзтезмәсенә аңлатма бирелә һәм аны тормышка ашыру юллары күрсәтелә. Пассив кеше, агрессив кеше һәм үз-үзенә ышанган кеше фикерләре чагыштырыла, үз фикерләреңне тәртипкә салу күнегүләре башкарыла, үз өстеңдә эшләү юллары бирелә, позитив фикерләүнең кеше тормышына уңай роле ассызыклана. Укучылар алган белемнәрне эшлекле уен ярдәмендә практикада кулланалар.

**17 нче дәрес**. Алдагы дәреснең дәвамы буларак, ачулану һәм ярсу кебек тискәре психиканың көтелгән эшкә тискәре тәэсире мисаллар ярдәмендә исбатлана, үз өстеңдә эшләү юллары кабатлап кителә һәм тезислар формасында дәфтәрләргә теркәлә.

**18-19 нчы дәресләр**. Укытучы эшлекле аралашуның төрле формаларын күрсәтә, этикет кагыйдәләрен һәм нормаларын китерә: аш-су өстәле артында аралашу, танышу, үзара ихтирамлылык, эшлекле әңгәмә, кием-салым, эшкә кабул иткәндә кайбер киңәшләр, транспортта барганда аралашу һ.б. Укучылар дәрестә алган күнекмәләрне эшлекле уен, конспект, тезислар ярдәмендә ныгыталар.
**20 – 22 нче дәресләр**. Укытучы эшлекле аралашуның язма формаларын бирә, укучылар текстлар төзиләр, эш кәгазьләре үрнәкләре язалар (гариза, беркетмә, белешмә, белдерү, тасвирнамә, тәрҗемәи хәл һ.б.).
**23-24 нче дәресләр.** Язма һәм телдән сөйләмнең төрләрен укучыларга җиткерү, үзенчәлекләрен аңлату. Язма сөйләм үрнәкләре белән таныштыру. Иҗади эшләр башкару.
**25 нче дәрес**. Эшлекле этикетның татарча-русча вариантлары чагыштырыла. Үрнәк сүз формалары, сүзтезмәләр бирелә, рольле уен, эшлекле уен ярдәмендә укучылар практик күнекмәләр алалар.
**26-27 нче дәресләр.** Татар һәм рус телләре грамматикасының үзенчәлекләрен, охшаш һәм аерымлыкларын укучылар үзләре күрсәтәләр,этикет формаларын китерәләр, җөмләләр төзиләр, тәрҗемә эше белән шөгыльләнәләр.
**28 нче дәрес.** Риторика фәненең үзенчәлекләрен ачыклау, текстлар төзү. Мәктәптә риторика дәресләренә керү, нәтиҗәләр ясау.
**29 нчы дәрес.** Рәсми эндәшү формаларының үзенчәлекләрен өйрәнү, төрле ситуатив күнегүләр эшләү.
**30 нчы дәрес**. Төрле очракларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, ситуатив күнегүләр эшләү. Кеше булып кала белү очраларына мисаллар китерү.
**31-32 нче дәресләр**. Лидер булу үзенчәлекләре, лидерлык сәләтен ачу билгеләре күрсәтелә. Укучылар мисаллар, текстлар өстендә эшлиләр, конспект,тезислар төзиләр.
**33 нче дәрес**. Эмоциональ интеллект турында мәгълүмат бирелә, аның сыйфатлары күрсәтелә, укучылар бу сыйфатларны дәфтәрләренә теркәп баралар. Кеше факторы төшенчәсе аңлатыла, заман җитәкчесенә хас кайбер киңәшләр һәм ул белергә тиешле төп принциплар тезислар рәвешендә дәфтәрләргә теркәлә. Бәхетле кешеләргә характеристика бирелә. Рухи тормыш нигезләренең гомуми уңышлы яшәешкә тәэсире аңлатыла. Укучыларга риваять тыңларга тәкъдим ителә, аны укучылар үзләре анализлыйлар.
**34 нче дәрес**. Яхшы тыңлаучы булу серләре китерелә, киңәшләр бирелә. Укучылар аларны дәфтәрләренә теркиләр. Нәтиҗә ясала, түгәрәк йомгаклана.

## ҮРНӘК ДӘРЕС КОНСПЕКТЛАРЫ

### 18 нче дәрес

**Тема**. Сөйләм культурасы. Текст редакцияләү.

**Максат**: ” Сөйләм культурасы “ темасы буенча белемнәрне гомумиләштерү һәм тирәнәйтү, текст редакцияләргә өйрәтү, “Microsoft Word” программасында эшләү күнекмәләрен үстерү, туган телне яратырга һәм нечкә итеп тоярга, аның сүз байлыгын дөрес файдаланырга өйрәтү.

**Җиһазлау.** Дәрес компьютер классында үткәрелә. Компьютерларга редакцияләү өчен текст кертеп куела. Видео һәм аудиомагнитофон. “ Туган як бизәкләре “ тапшыруыннан видеофрагмент. Тестлар. Карточкалар. Плакатлар.

**Дәрес барышы**.

I.Оештыру. Уңай психологик халәт булдыру.

а) Р.Миңнуллинның “Туган телемә” шигыре язмасын тыңлау.

б) Укытучының кереш сүзе.

- Исәнмесез, укучылар! Әле генә нинди матур шигырь тыңладык. Аның эчтәлеге бүгенге дәрес темасы белән бик тәңгәл килә: без туган тел турында сөйләшүне дәвам итәбез. Кешенең кем икәнен беләсең килсә, аның сөйләменә игътибар итәргә кирәк. Без һәрвакыт матур итеп, саф татарча сөйләшүчеләргә сокланабыз. Моңа ирешү өчен, телне бик яхшы белергә, тоярга, гасырлар буе тупланып килгән сүз байлыгын дөрес файдаланырга кирәк. Искә төшерик әле, сөйләмгә нинди таләпләр куела ?

II. Белемнәрне тигезләү.

*а) Укучыларның җаваплары тыңлана һәм тактага плакатлар беркетелә бара:* Сөйләм төгәл булсын, сөйләм аңлаешлы булсын, сөйләм саф булсын, сөйләм җыйнак булсын, сөйләм аһәңле булсын.

б) - Бик дөрес , балалар. Без бу таләпләрне боза торган нинди хаталар җибәрәбез соң?
Кызганычка каршы, сөйләм хаталары бик еш очрый. Менә бер мисал.

*“ Туган як бизәкләре “ тапшыруыннан өзек – колхоз рәисе чыгышы карала. ( 2 минут)*

--Укучылар, нинди хаталар ишеттегез?. Әйе, алынма сүзләр урынсыз күп кулланыла. Монда Дәрдемәнд сүзләрен китерү урынлы булыр иде:

Катыштырма вәләкин телгә телне
Тел уйнатмак наданлыктан гамәлдер.

Хаталар китмәсен өчен, уйлап сөйләү, язганыңны кат-кат тикшерү мөһим.

III. Белем-күнекмәләрне ныгыту.

- Без хәзер текст редакцияләрбез- сөйләм хаталарын табып, төзәтербез. Сезгә өйрәнгән белемнәрегезне файдаланырга кирәк булыр.

*Укучылар компьютерларга утыра. Текст укыла. Эчтәлеге буенче кыскача әңгәмә үткәрелә. Мөстәкыйль эшлиләр.*

Район киңәшмәсендә.

Вакыт кич. Әкрен генә ябалак кар ява.Район главасы колхоз рәисләрен киңәшмәгә җыйды.Алар бүгенгесе көнне әһәмиятле булган мәсьәләләрне хәл итәргә җыеналар.

Беренче булып “ Шахтер “ колхозыннан килгән Г.Мәрдәновка сүз бирелде:

Безнең сөт сату буенча показательләребез начар түгел дип әйтәсем килә.Барлык крупный рогатый скот прогулкага чыга, ашатырга җитә. Көненә 2.5 тонна сөт реализовать итеп барабыз.Дояркалар да тырышып эшли. Эшләгәненә карап хезмәт хакы да яхшы гына чыга. Ә менщ производство мясада эшлисе эшләр эшләнмәгән әле, резервлар җитәрлек.

Аннары сүз салам тарттыру мәсьәләсенщ күчте.Глава 10 декабргә бу эшне төгәлләү мәсьәләсен куйды. Дөрестәндә, кар тирәнәйгәч бу эшне башкарып чыгу авыр булачак.

“ Күңгәр “колхозы рәисе агымдагы ремонт эшләре турында информцаия бирде:

Тракторларны, сеялка һәм башка тагылма коралларны үзебездз ремонтлыйбыз.Мастерскойлар җылы, запчасть белән дә өзеклек булганы юк.

Киңәшмә соң гына тәмамланды. Хакимият бинасы каршысына җыелган машиналар авылларга таралыштылар.

*Алдан бетергән укучыларга өстәмә эш:*

“ Табигаттә бер артык һәм бер кирәксез әйбер юк “ дигән сүзне ишеткәнегез бардыр сезнең. Күптән түгел үткәрелгән балалар иҗаты выставкасы моңа мисал булып тора. Анда ясалган күргәзмә табигый материаллардан ясалган иде. Түгәрәккә йөргән балалар төрле әйберләрне көнкүрештән калгач та файдаланып булганлыгын исбатлаганнар. Миләштән ясаган муенсалар кызларга барса, полиэтилен шешәләр нәрсәгә генә бармый ! Балаларга иҗади бирем дә бирелгән иде , беренче булып килгән укучылар шуны сөйләп күрсәтте.

**Физкультминт. Күзләрне ял иттерү.**

Үзбәя. Укучылар үз эшләрен текстның дөрес варианты белән чагыштырып тикшерәләр. Хаталар анализлана.

IV. Рефлексия. “ Сөйләм культурасы “ темасы буенча тестлар эшләү.

1. Кайсы җөмләдә стилистик хата бар?

А) Бу галстук синең кайсы күлмәгең белән барыр икән?
Б) Гомерләр уза икән ул!
В) Дәү әниебезнең урыны җәннәттә булсын!
Г) Ләкин мин боларны кайдан алыйм?

2.Кайсы җөмләдә стилистик хата бар?

А)Тышта ниләр бар икән?
Б) Храм музейга әверелдерелә.
В)Шомыртлар чәчәк ата.
Г) Бәхет дигәннәре шулдыр инде ул!

3.Татар телендә кайсы пар сүзләр юк?

А) мәхәббәт – мәһабәт;
Б) зират – зыярат
В) ахыры – ахры;
Г) таләп – тәләп.

4. Татар телендә кайсы пар сүзләр юк?

А) гыйбрәт – гыйбарәт;
Б) тәкбир – тәгъбир;
В) хуш – һуш;
Г) тәэсир – тәкъсир.

5. Кайсы җөмлә рус теле калькасы түгел?

А) Яңа еллар котлы булсын!
Б) Мин Сезнең алда бурычлы.
В) Нинди язмышлар белән?
Г) Сезгә үз яшегезне биреп булмый.

6. Кайсы сүзтезмә дөресрәк?

А) авыруның шифасы;
Б) даруына күрә шифасы;
В) шифасының дәвасы;
Г) даруның шифасы.

7. Кайсы сүзтезмә дөрес?

А) янгын күзәтелде;
Б) авыл кешесе;
В) костюм – чалбар;
Г) быелгысы елда.

8. Кайсы җөмләдә гарәп алынмасы дөрес кулланылмаган?

А) Иншалла, мәшәкатьле юл артта калды.
Б) Насыйп булса, барып җитәрбез.
В) Һәр авыруның дәвасы була.
Г) Ул сугышта шәһит китте.

9. Сөйләм культурасы нәрсә ул?

А) әдәби телнең язма һәм сөйләмә формадагы нормаларын үзләштерү;

Б) тел белеменең тел нормаларын өйрәнүче тармагы;

В) кешеләрнең әдәпле сөйләшүе;

Г) А һәм Б вариантлары.

V. Өйгә эш бирү.Карточка белән эш. Сөйләм хаталарын төзәтеп язарга:

Ә башта әйткәнемчә, миңа килгәндә, минем киләчәк юлым шушы җыелыштан соң икенче көнне хәл ителде. Икенче көнне базар көн булып, без мәктәпкә бармадык. Иртән торып, ике апа да эшкә киткәч (зурысы ат белән тирес чыгара, кечесе кар тотуда иде), мин киенеп, абзар чистартырга чыгарга гына дип торганда, идарәдән йомышчы Мәймүнә апа килеп, мине тиз генә районнан килгән судья чакыра дип әйтеп китте. Мин, Мәймүнәттәйне дә узып китеп, идарәгә йөгердем. Әлбәттә, кичә колагыма иелеп әйткән йомшак тавышын, иңсәмә куеп кына алган җылы кулын ишетмәсәм - тоймасам, мин каушап - куркып, коелып төшәр идем, ләкин мине бүген, идарәгә чабып барганда, ниндидер ашкынулы дулкын биләп алды. Мин шул дулкын эчендә идарәгә барып кердем. (Хәсән Сарьян)

VI. Йомгаклау. Билгеләр кую.

Менә , укучылар, без “ Сөйләм культурасы “ темасы буенча үткәннәрне практик кулланып карадык. Бу эш белән кайбер һөнәр ияләре көн саен шөгыльләнә, кемнәр дип уйлыйсыз? ( Редакция хезмәткәрләре, укытучылар...) Бик дөрес. Редакцияләрдә бу эшне редакторлар, корректорлар башкара. Бәлки кайберләрегез киләчәктә укытучы, журналист, корректор булыр, бу белемнәрне эшендә кулланыр. Алай гына да түгел, һәркайсыгыз, Дәрдемәнд шигырендәгечә, “уен уйдырып салырлык булсын”. Кайда гына укысаң да, эшләсәң дә , кешеләр белән сөйләшә белү , дөрес язу бик мөһим. Юкка гына урыслар “ Чистое слово “ программасы өстендә эшләмиләр. Без дә үз телебезне бай һәм саф килеш сакларга тиеш. Мин сезнең киләчәктә туган телебезне дә , компьютерны да бик яхшы белүчеләр булуыгызны телим.

**19 нчы дәрес**

**Тема:** Эшлекле аралашу этикеты.

**Максат:** Эшлекле аралашуның төрле формаларын, танышу һәм таныштыру тәртибе кагыйдәләрен өйрәнү; эшлекле әңгәмәнең структур элементларын үзләштерү һәм эшлекле әңгәмә оештыру; практик күнекмәләр бирү.

**Җиһазлау**: Кагыйдәләр һәм киңәшләр җыелмасы, тарату материаллары.

ДӘРЕС БАРЫШЫ

I. Кереш сүз һәм укучылар чыгышы.

Укытучы (рольгә керә). Исәнмесез! Сезне кем дип белик? Нинди максат белән килдегез? Тыңлыйм сезне.

Укучылар. Без, 10нчы сыйныф укучылары, “Эшлекле аралашу этикеты” дигән тема буенча әңгәмә оештырырга һәм аралашуның кайбер формаларын, кагыйдәләрен үзләштерергә телибез. Бу эштә безгә сезнең ярдәмегез кирәк иде.

Укытучы. Рәхим итегез! Дәресне башлыйбыз. Узган дәрестә сезгә, өй эше итеп, кайбер сүзләрнең, сүзтезмәләрнең мәгънәсен белеп килергә кушылган иде. Нәрсә ул эшлекле аралашу? Нәрсә ул этикет? Нәрсә ул эшлекле әңгәмә?

1нче укучы. Эшлекле аралашу – ул эш урынында җитәкче белән хезмәткәрләрнең конкрет эшкә кагылышлы аралашуы.

2нче укучы. Этикет – кабул ителгән аралашу нормалары һәм кагыйдәләре җыелмасы.

3нче укучы. Эшлекле әңгәмә – конкрет эшкә кагылышлы телдән оештырылган әңгәмә. Аның максатлары төрле булырга мөмкин.

II. Эшлекле аралашу уңышлы булсын өчен алшартлар. ( Укытучы сүзе )

1. Әңгәмәдәш турында иң беренче тәэсир берничә секунд эчендә формалаша. (Кием, прическа, күз карашы, йөз-бит торышы, жестлар, тавыш тоны һәм үз-үзеңне ышанычлы тоту)
2. Тактлы булу, этикет һәм яхшы манера саклау.

III. Эшлекле аралашуның төрле формалары.

1. Танышу.
2. Гомуми ихтирамлылык: а) елмаю – аралашуның халыкара формасы. Ул дустанә мөнәсәбәтне һәм эчкерсез булуны аңлата. Ихтирамлылыкның төрле илләрдә башка төрле формалары да кулланыла. (Укучыларга аңлатыла); б) кул кысу (мөселман илләрендә хатын-кызның кулын кысу рөхсәт ителми); в) күзгә-күз караш (төрле илләрдә төрлечә кабул ителә);
3. Бүләк бирү: а) төрле сәбәп белән (проект тәгәлләнү, дини яки дөньяви бәйрәм белән котлап, эш буенча күтәрелү, истәлекле вакыйга (туган көн, туй көне, юбилей, бала туу, пенсиягә чыгу) уңае белән; кемнедер үпкәләтү, рәнҗетү, очрашуга килми калмаганда; проектны тормышка ашырырга булышучыларга); б) Нәрсә бүләк итәргә? (деликатеслар, чәчәкләр, кино-театрга, концертка билетлар, торт, вино яки коньяк (бу очракта кешенең теләген искә алырга кирәк).
4. Аңлашу – җитәкче өчен мөһим сыйфат: а) үз кул астындагыларның шәхси сыйфатларын өйрәнү; б) аларга хезмәт итәр өчен уңай шартлар тудыру; в) инвалидлар белән аралашу үзенчәлекләрен истә тоту.
5. Эш сорап әңгәмә (собеседование) үтү: а) әзерлек эшләре алып бару (компания турында информация туплау, компаниянең тарихын белү, компаниянең йөзе (имидж), перспективалары, проблемалары белән таныш булу (информация мәгълүмат чаралары аша тупланган булса яхшы, ә яшерен чыганаклардан түгел); б) әңгәмә өчен киемең дә эш стилендә булу (һәр компаниянең дә үз стиле); в) әңгәмә үткәндә тулы бер ритуал саклау (үзеңне яхшы күрсәтү өчен, укучыларга киңәшләр таратыла).
6. Аш өстәле артында аралашу (этикет, өстәлгә ашамлыклар кую тәртибе).
7. Транспортта аралашу.

IV. Эшлекле уен өчен текст төзү.

Укытучы. Сез үзегезне җитәкче итеп күзаллагыз. Кайсы фирма, оешманың җитәкчесе булыр идегез? Эш эзләп килгән кешегә әңгәмә вакытында нинди сораулар бирергә уйлыйсыз?

Укучылар сораулар төзиләр.

Укытучы. Хәзер үзегезгә партнер сайлагыз һәм бер-берегез белән рольләр алмашып, әңгәмә үткәрегез. Әңгәмә вакытында үзегезне ышанычлы, иркен тотыгыз. (2-3 парны тыңларга мөмкин).

Укытучы – укучы арасында эшлекле әңгәмә оештырырга була. Укучыларга әңгәмә үрнәкләрен алдан төзеп таратырга мөмкин.

Укытучы – эш бирүче, укучы– эш сораучы һ.б.

V. Дәресне йомгаклау.

1. Дәреснең иң әһәмиятле тезисларын кабатлау, ассызыклау.
2. Сораулар һәм биремнәргә җавап бирү.
3. Дәфтәрләргә теркәп кую.

VI. Өй эше бирү.

1. Язма формада эшлекле аралашу формаларын ачыкларга.
2. Сорауга җавап әзерләргә: нинди эш кәгазьләрен беләсез?

**20 нче дәрес**

**Тема:** Язма формада эшлекле аралашу.

**Максат:** Эшлекле аралашуның язма формалары белән танышу, тәрҗемәи хәл, гариза язарга өйрәнү, эшлекле әңгәмә оештыру; практик күнекмәләр бирү.

**Җиһаз:** Кагыйдәләр һәм киңәшләр җыелмасы, тарату материаллары.

ДӘРЕС БАРЫШЫ:

1.Дәреснең темасы, максаты белән укучыларны таныштыру.

2. Укытучы сүзе:

Татар телендә рәсми эш кәгазьләре бик күптән барлыкка килгән. Үзенең чыганаклары белән алар турыдан-туры Алтын Урда һәм Казан ханлыклары чорларындагы канцелярия эшчәнлегенә барып тоташа һәм 19 нчы гасыр ахырына кадәр килеп җитә. 17 — 18 нче йөзләрдә һәм 19 нчы йөзнең беренче яртысында иске татар әдәби теле рус дәүләтенең шәрык илләре белән дипломатик мөнәсәбәтендә зур әһәмияттә ия булган. Мәскәүдә дипломатик хатлар, гадәттә, русча һәм татарча төзелгәннәр. Рус дәүләте исеменнән Кырымга, Төркиягә,Урта Азия халыкларына һәм шулай ук Иран, Һиндстан, Монголиягә ул чорда җибәрелгән дипломатик документлар, башлыча, иске татар телендә язылганнар. 17 — 18 нче йөзләргә караган татарча рәсми документларның икенче төркемен рус дәүләтенең үз эчендәге һәртөрле административ язышу үрнәкләре төрле донесениеләр, крестьяннар исеменнән язылган гаризалар, күмәк хатлар, юридик документлар (дәгъванамәләр, милек бүлешү турындагы язмалар, солыхнамәләр, метрика кенәгәсеннән күчермәләр, указлар, манифестлар, боерыклар, халыкка өндәмәләр, югарыда утыручыларга юлланган рапортлар һ.б.) тәшкил итә.
Татар телендә язылган әлеге документлар Мәскәү һәм Казан архивларында да сакланып калганнар. Татар теле республикабызда рус теле белән бергә дәүләт телләре дип игълан ителгәч, туган телебездә рәсми эш кәгазьләре кулланылышы бик нык киңәйде.

Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, һәркем, тормышның кайсы гына тармагында эшләсә дә, үзенең тәрҗемәи хәлен, үтенечен, ышынычын, кылган гамәленең эчтәлеген һ.б. язма рәвештә башкаларга да җиткерә белергә тиеш. Эш кәгазьләрендә җөмләләр кыска, әмма төгәл эчтәлекле, ачык аңлаешлы була.

3. Автобиография язу тәртибе белән танышабыз.

Тәрҗемәи хәлем (автобиография) – үз тормышыңның төп вакыйгалары турында кыскача хроникаль белешмә рәвешендә язу. Автобиографияне укырга кергәндә, эшкә кабул иткәндә, хәрби хезмәткә чакырылганда, бүләккә тәкъдим иткәндә һ.б.ш. очракларда таләп итәләр. Автобиография текстында түбәндәгеләр күрсәтелә:

- язган кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;
- туган урыны, вакыты (ел, ай, көн);
- кайда укуы;
- хезмәт эшчәнлеге, хәзерге вакытта эшләгән урыны;
- башкарган җәмәгать эше;
- гаилә хәле турында мәгълүмат.

Автобиография беренче зат исеменнән языла.

4. Үрнәк буенча язарга өйрәнү.

Тәрҗемәи хәлем

Мин, Харисова Гөлназ Айрат кызы, 1994 нче елның 4 нче маенда Татарстан Республикасы Чистай шәһәрендә туганмын.

2000 нче елда мин 2 нче татар гимназиясенең беренче сыйныфына укырга кердем. Хәзер 10 нчы сыйныфта укыйм. Мин әдәбият, тарих, математика фәннәрен яратам.

Безнең мәктәптә төрле түгәрәкләр эшли. Мин "Оста куллар", "Яшь хәбәрчеләр" түгәрәкләренә йөрим.

Мин – гаиләбездәге ике баланың беренчесе. Әтием Айрат заводта, ә әнием татар гимназиясендә укытучы булып эшли. Сеңлем шул ук гимназиянең 3 нче сыйныфында укый.

20 нче май, 2010 нчы ел. Имзам: ________________

4. Гариза язу тәртибе белән танышу:

Гариза ул – язма рәвештә рәсми формада язылган шәхси үтенеч (эшкә, уку йортына һ.б. кабул итү, нәрсәгәдер рөхсәт сорау һ.б.).

Гариза кулдан языла. Ул билгеле бер оешмага, хезмәт урынындагы кешегә (затка) адреслана.

5. План буенча сөйләп карау.
1. Үтенеч белән мөрәҗәгать ителгән оешма яки шәхес адресы.
2. Фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм эш урынындагы дәрәҗәсе.
3. Документның исеме – гариза.
4. Үтенеч-сорауның кыскача эчтәлеге.
5. Гариза язылу көне.
6. Гариза язучының имзасы.

6. Өй эше. Үрнәк буенча гариза язып килергә.

Казан шәһәренең “Тасма”
берләшмәсе директоры Г.Г.Вәлиевкә
Казан шәһәре Татарстан урамы,
45 нче йортның 78 нче фатирында
яшәүче Харисова Зәкия Зәйни
кызыннан

гариза

Мин, Харисова З.З., Сездән вакытлыча гына булса да улым Харисов Р.Ф. эшкә алуыгызны сорыйм.

3 нче март, 2010 нчы ел. Имзам: ______________

7. Йомгаклау.

**21 нче дәрес**

**Тема:** Язма формада эшлекле аралашу.
**Максат:** Эшлекле аралашуның язма формалары белән танышу, хат язарга өйрәнү, эшлекле әңгәмә оештыру; практик күнекмәләр бирү.
**Җиһаз:** Кагыйдәләр һәм киңәшләр җыелмасы, тарату материаллары.

ДӘРЕС БАРЫШЫ:

1.Дәреснең темасы белән укучыларны таныштыру. Максатыбыз: хат язарга өйрәнү.Белемле кеше эш кәгазьләрен дә яза белергә тиеш. Аларның үзләренә генә хас язу үзенчәлекләре бар: җөмләләр төгәл эчтәлекле, кыска, аңлаешлы була.

2. Хат язарга өйрәтү.

Хат – тормышта бик еш очрый торган эш кәгазьләренең берсе. Ул шәхси һәм нинди дә булса эшкә мөнәсәбәтле булырга мөмкин.

Хат ничек языла? Хат язу үрнәген аңлатып китү.

А) Хат кешегә багышлануы белән башланып китә, ягъни исәпләшү, мөрәҗәгать була.
“Исәнме, кадерле әнием!”
“Исәнмесез, хөрмәтле укытучым Йолдыз апа!”
“Исәнме, якын дустым Ирек!”
Болай да башланырга мөмкин:
“Хәерле көн, газиз әнием!”
“Хәерле кич, дустым Нурия!”
Б) Хатны алырга тиешле кешенең хәлләрен, сәламәтлеген сорашу кирәк булыр.

“Хәлләрегез ничек? Исән-сау гына яшисезме? Сездә нинди яңалыклар, үзгәрешләр бар?”

В) Үз хәлләрегез белән таныштыру башлана.

“Мин исән-сау. Әйбәт кенә укыйм. Мәктәптә бик күңелле: дәресләр кызык үтә, түгәрәкләр һәм кичәләр була.

Күптән түгел генә “Җырлыйк әле” дигән әдәби-музыкаль кичә үткәрдек. Тамашачылар бик ошаттылар.”

Г) Хатны язучы үз тормышында булган вакыйгалар белән тулырак таныштыра.

Д) Соңыннан саубуллашып, исемен һәм язылу вакытын куя.

3. Укучыларга түбәндәге эшләр тәкъдим ителә.

1.Авылыгыздагы (шәһәрдәге) сугыш яки хезмәт ветеранына котлау хаты язарга.

2.Укыган китабыгыз яки караган фильм турында дустыгызга хат язарга.

3.Үз тормышыгызда булган 1-2 вакыйга турында әйтеп туганыгызга хат язарга.

***Хат үрнәге.***

Исәнме, кадерле дустым Энҗе!

Язган хатыңны алып укыдым. Рәхмәт. Энҗе, хәлләрегез ничек? Ничек яшисез? Авырмыйсызмы? Сездә нинди яңалыклар бар?

Мин исән-сау. Әйбәт укыйм. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен яратам, күп әсәрләр укыйм, кичәләрдә катнашам. Бөек шагыйребез Муса Җәлилгә багышланган кичә үткәрдек. Кичәнең исеме дә “Гомерем минем моңлы бер җыр иде, үлемем дә яңгырар җыр булып.”

Кичә бик әйбәт булды. М.Җәлилне искә алу көне иде. Н.Җиһанов белән иҗат иткән музыкаль әсәрләрен тыңладык. Шигырьләрен укучылар да, мин дә яратып сөйләдек. Укытучы апа безне бик мактады: “Татарча матур сөйләдегез”- диде. Ярый, дустым, сау бул. Хат яз. Иң изге теләкләр белән: Резидә.

20 нче октябрь 2010 нчы ел.

4. Өйгә эш. Мәкалә, аңлатма язуы, сыйфатлама сүзләренең мәгънәләрен сүзлектән карап килергә.

5. Йомгаклау.

**22 нче дәрес**

**Тема:** Язма формада эшлекле аралашу.

**Максат:** Эшлекле аралашуның язма формалары белән танышу, мәкалә, аңлатма язуы, сыйфатлама язарга өйрәнү, эшлекле әңгәмә оештыру; практик күнекмәләр бирү.

**Җиһаз:** Кагыйдәләр һәм киңәшләр җыелмасы, тарату материаллары.

ДӘРЕС БАРЫШЫ:

1.Дәреснең темасы, максаты белән укучыларны таныштыру.

2. Өйгә эшне тикшерү. Нәрсә ул мәкалә, аңлатма язуы, сыйфатлама?

**Мәкалә** - вакытлы матбугатка (газета,журнал һ.б.) көндәлек вакыйгалар, эш-гамәлләр турында язылган хәбәр. Нәрсәләр турында язарга:

А) көзге эшләрдә катнашу;

Б) кызыклы кичәләр;

В) сугыш һәм хезмәт ветераннары;

Г) оста куллы кешеләр;

Д) игелек эшләүчеләр һ.б.

Тормышыбызда төрле хәлләр, вакыйгалар белән кайнап тора. Һәрберсе турында да язарга була. Хәбәр кызыклы да булсын, яңалык та әйтсен, нәрсәгәдер өйрәтсен дә, гыйбрәт алырлык та булсын.

**Сыйфатлама** – хикәя төзү. «Сыйфатлама” сүзенең төзелешенә игътибар итик.

Сыйфат + лама – димәк, нindидер күренешнең, вакыйганың, әйбернең, кешенең үзең яхшы белгән сыйфатлары тупламасы (кайбер язмаларда “сыйфатнамә” дигән сүз дә очрый. Бу сүз рус телендәге “характеристика” дигәнне аңлата).

Сыйфатламаларны эчтәлекләре буенча берничә төркемгә бүлеп карарга була:

А) табигать күренешләре

Б) әдәби геройлар;

В) яхшы белгән кешең (дустың, күрше, әни, абый ...)

**Раслама** – нәрсәне булса да алуны раслаган кешенең фамилиясе язылган, шәхси имзасы (подпись) куелган документ.

Раслама – эш кәгазьләренең бер төре. Акча, кыйммәтле әйберләр, документлар алганда языла. Ул түбәндәге өлешләрдән тора:

1) документның исеме;
2) раслама язучының исеме, әтисенең исеме, фамилиясе;
3) әйбер алынырга тиешле оешманың атамасы яки кешенең исем-фамилиясе;
4) алынган, алыначак әйбернең күләме, саны башта цифр белән, аннары җәяләр эченә сүз белән языла;
4) нинди документ нигезендә алына;
5) алучының шәхси имзасы, расписка язылган көн, ел, вакыт.

3. ***Үрнәк буенча раслама язу:***

Раслама.

12 нче гыйнвар 2005 нче ел.

Мин, 8 нче сыйныф укучысы Сабироова Алсу, Чистай районы Мөслим төп гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле укытучысы Закирова Гөлия Нургаяз кызыннан укып тору өчен “Туган ягым – тау ягы” дигән китап алдым. Реферат язу өчен бирелде.

Сабирова Алсу.

5. Өйгә эш. Мәкалә яки сыйфатлама элементлары белән хикәя язарга.
6. Йомгаклау.

**Түгәрәк эшенең нәтиҗәлелеге**

“Аралашу этикеты” дигән түгәрәк планы Чистай шәһәренең 3 нче гимназиясендә апробацияләнде. 5-10 нчы сыйныф укучылары түгәрәккә бик теләп йөриләр...

Балаларны матур, дөрес, төгәл итеп сөйләргә өйрәтү түгәрәкнең төп бурычларыннан санала. Бер яктан, сөйләм аң, фикерләү үсеше белән тыгыз бәйләнгән, сөйләм ярлылыгы фикер үсешен тоткарлый. Икенче яктан, телне яхшы белми торып сүз сәнгате булган әдәбиятны да аңлап, тоеп, кичереп булмый. Шуңа күрә укучыларны телен баету һәм камилләштерү игътибарга алынырга, аның өстендә махсус эш алып барылырга тиеш.

Телдән дөрес, матур сөйли белгән бала язмача да үз фикерен тиешенчә әйтә ала һәм киресенчә. Телгә игътибарлы, белемле укучы үзенең уен телдән дә, язмача да төгәл әйтә белер. Баланы дөрес сөйләшергә өйрәтү – бик дәвамлы эш: һәр дәрестә, тәнәфестә, өйдә, төрле чараларда, кыскасы, һәрвакыт бара торган эш. Түгәрәкнең әһәмияте менә шунда инде. Түгәрәккә йөргән балаларның сөйләм телләре байый, аралашу әдәбе яхшыра. Укучылар башкалар алдында, сәхнәдә чыгыш ясарга өйрәнәләр. Үз-үзләренә ышаныч арта, иҗади сәләтләре үсә. Фәнгә кызыксынулары арта, шуңа күрә бу түгәрәккә йөрүче балаларның олимпиадаларда, төрле бәйгеләрдә катнашырга теләкләре уяна. Соңгы 3 елда түгәрәккә йөрүче балалар төрле бәйгеләрдә уңышлы чыгыш ясауларын әйтеп үтәсем килә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк ки, укучыларның сөйләме түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш: фикер эзлекле белдерелергә, төп фикер ачылырга һәм темага туры килергә, фикер грамматик яктан дөрес булып, сөйләмдә билгеле бер темп сакланырга тиеш.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, укыту процессында укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү телдән оештырыла, ә язма сөйләм телне тагын да тирәнрәк белүне сорый, чөнки укучыларның язу күнекмәләре дә тиешле дәрәҗәдә үсеш алган булырга тиеш. Түгәрәкне тәмамлаганда, укучылар язма рәвештә дә үз фикерләрен белдерергә күнеккән булырга тиешләр.

**Тарату материалы**

## ӘҢГӘМӘ ҮТКӘНДӘ ҮЗЕҢНЕ ЯХШЫ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН КИҢӘШЛӘР

1. Кул кысышу өчен кулыңны әүвәл үзең суз! Бу – үз-үзеңә ышаныч билгесе, аны яшерергә кирәкми.
2. Үзеңне контрольдә тот. Әңгәмә вакытында тәмәке тартма, баллы әйберләр капма, резинка чәйнәмә.
3. Җитәкчегә исеме белән эндәшмә. Ул үзе рөхсәт итсә генә мөмкин. Ничек эндәшергә икәнен сорама, ул үзе тәкъдим иткәнен көт я секретаре киңәшләренә колак сал. Җитәкче үз исемен әйтмәсә, аңа урынындагы дәрәҗәсе буенча эндәш, әфәнде, ханым, туташ сүзләрен өстә.
4. Хәрәкәтләреңне контрольдә тот. Утырырга тәкъдим итмәсәләр, басып тор, тәкъдим иткәнне көт. Утыргач, җәелеп китмә, туры утыр. Курку хисе булмасын, үзеңне ышанычлы тот, туры кара, күз карашың да ышанычлы булсын. Ачык позада булырга тырыш, ягъни кулларны тоташтырырга, кулны күкрәккә кушырырга, аякларны аяк өстенә куярга ярамый. (Алдагы дәресләрдә өйрәнгән киңәшләрне кара).
5. Тыңлый белергә өйрән. Бүлдерергә тырышма, сөйләп бетергәнне көт. Сорауга җавап бирер алдыннан уең белән генә 3-5кә кадәр сана. Бу акыллы җаваплар бирер өчен һәм әңгәмәдәшнең сөйләп бетергәненә тулы ышану өчен кирәк.
6. Үзеңне үз-үзенә нык ышанган кеше итеп күрсәт. Җитәкче синең компаниягә файда китерә алырлык кеше икәнеңә төшенергә тиеш. Ышанычлы җаваплар синең нәкъ менә аңа кирәкле кеше булуыңны күрсәтә. Ләкин үзеңне өстен куйма, бәйләнчек булма, шуның белән үзеңне читкә этәрергә юл куйма.
7. Әңгәмә үткәрүченең тактикасын аңларга тырыш. Артык сүзләр ычкындырма, ачылып китмә, үткәндәге тормышыңны сөйләмә. Әңгәмә үткәрүчеләр, гадәттә, басым астында артыгын да таләп итәрләр. Ышанычлы рәвештә тиешлесен генә әйт.
8. Гади генә сорауларга да сакланып кына җавап бир. Алар башка нәрсәне күздә тотып бирелергә мөмкиннәр. Артык җәелеп китмә, кирәкмәгән сүз сөйләмә, бигрәк тә алдагы эшеңә кагылышлы булганнарын сатма. Җитәкче синең ышанычлы кеше булуыңа инанырга тиеш.
9. Ялганлама, үз мөмкинлекләреңне арттырып сөйләмә. Ялган бер беленә ул. Сез эшсез калырга мөмкин. Элеккеге җитәкче, хезмәт хакы, уңышлар турында дөресен сөйләргә кирәк.
10. Юмор белән артык мавыкмагыз. Юмор бернәрсә дә бирми. Сезгә анекдот яки мәзәк сөйләсәләр, көлегез, әмма үзегез дәшми калыгыз, мәзәк сөйләп маташмагыз. Нәтиҗәсе сез көткәнчә булмаска мөмкин.
11. Әңгәмәдәшнең вакытын күп алмагыз, сораулар бирмәгез. “Әңгәмәгез өчен рәхмәт”, “Сез бик күңелле әңгәмәдәш булдыгыз” кебек җөмләләр әңгәмәнең ахырына якынлашканын күрсәтә. Әйтер сүзегез калса, соңыннан да әйтергә була бит.
12. профессиональ кеше булуыгызны исбатларсыз. Әңгәмә вакытында бигрәк тә нәрсә ошаганы турында әйтергә онытмагыз, моны компания эшчәнлеге белән бәйләгез. Сез үзегезнең компаниядә эшләргә теләвегезне күрсәтегез. Мәсәлән: Әңгәмәне уңай нотада төгәлләгез. Сезгә бу компаниядә эшләве күңелле булачагы турында әйтегез, ни өчен биредә эшләргә теләгәнегезне мисаллар китереп аңлатырга мөмкин.
13. Җитәкчегә генә түгел, фирманың башка хезмәткәрләрендә дә яхшы тәэсир калдыр, синең хакта җитәкче алардан да сорашырга мөмкин.
14. Төгәл (пунктуаль) бул! Вакытында кил! Әңгәмәгә соңга калу – гафу ителмәслек хата.

**Мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары**

| Укытучы өчен методик әдәбият | Укучылар өчен әдәбият |
|---|---|
| 1.Курбатов Х. "Сүз сәнгате. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы". Казан: "Мәгариф" нәшр., 2002<br>2.Бенедиктова В. И. О деловой этике и этикете. – М., Институт новой экономики, 1994.<br>3.Бороздина Г.В. Психология делового общения. – М.: Инфра-М,1998.<br>4.Нигъматуллин М., Грамматик анализ. Алабуга, 2000.<br>5. Лингвистик анализ үрнәкләре.<br>6. Татар телендә тыныш билгеләре.<br>7. «Фән һәм мәктәп», «Мәгариф» журналлары, "Мәгърифәт", "Ачык дәрес" газеталары<br>- Диктантлар җыентыгы (төрле авторлар)<br>- Изложениеләр җыентыгы (төрле авторлар)<br>- Н.В. Максимов.Татар теленнән тестлар<br>8.Михайлов И.И. Этика: Учебное пособие для факультативных занятий в старших классах общеобразовательных школ. – Казань: Изд. "Магариф", 2003.<br>9. Культура устной и письменной речи делового человека: справочник. Практикум. 7-е изд., испр. – М., Флинта: Наука,2001.<br>10. Электрон ресурслар: http://gzalilova.narod.ru, sh2barda2006.narod.ru, muslum-tat.narod.ru, proshkolu.ru.<br>11. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. ЯрЧаллы, 1997.<br>12.Студентларның сөйләм күнекмәләрен үстерү һәм белемнәрен тикшерү өчен биремнәр. – Казан: КДАХА, 2005. – 63 б. | 1. Лингвистик анализ үрнәкләре.<br>2. Татар телендә тыныш билгеләре.<br>3. Н.В. Максимов.Татар теленнән тестлар<br>4. Гыймадиева Н., Нуруллина Р.Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы. К.: "Мәгариф", 2007.<br>5. Орфографик, орфоэпик һәм башка төр сүзлекләр.<br>6. Вәлиев З.В.. Эш кәгазьләре үрнәкләре. – Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1999.<br>7.Гольдин В.Е. Речь и этикет. – М.,1983.<br>8.Карнеги Дейл. Как завоевать друзей и оказывать влияние на людей. М.: Прогресс, 1995<br>9.Карнеги Дейл. Как вырабатывать уверенность в себе. – М.: Прогресс, 1995<br>10.Кузин Ф.А. Культура делового общения: практическое пособие для бизнесменов. – М.,2000.<br>11.Кадыров Ф.М. Русско-англо-татарский разговорник: деловое общение. – Казань: КСЮИ, 2000.<br>12.Фазлыев Җ. Иманлы бала. Казан, 2003.<br>13.Свитман Билл. Общаться успешно. – М., "ЭКСМО", 2007.<br>14.Южин, В.И., Энциклопедия этикета. – М.: РИПОЛ классик, 2007. |

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
3 нче гимназия муниципаль белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы **Фәтхетдинова Рузилә Ринат кызының** авторлык программасына

БӘЯЛӘМӘ

| | |
|---|---|
| **Исеме (темасы)** | "Аралашу этикеты" түгәрәге |
| **Инновациянең формасы** | Программа мәктәпнең үсеш программасы һәм өстәмә белем бирү планы нигезендә төзелә. Дәрестән тыш эшчәнлек формасында гамәлгә ашырыла. |
| **Инновациянең кыскача эчтәлеге** | Программа аңлатма язуы, программаның принциплары, максаты, бурычлары, календарь-тематик план, курсның эчтәлеге, максатка ирешү һәм бурычны үтәү өчен эш алымнары, нәтиҗәлелек һәм кулланылган әдәбият исемлеге, үрнәк дәрес конспектларын, тарату материалларын үз эченә алган зур күләмле кушымта өлешләреннән тора. |
| **Инновациянең яңалыгы (вариантның астына сызарга)** | Укучыларда лингвистик (тел), аралашу (коммуникатив), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру бүгенге көндә төп бурычларнгың берсе булып тора. |
| **Куллану масштабы (дәрәҗәсе)** | Район һәм республика дәрәҗәсендә гомум белем бирү мәктәпләрендә, төбәк һәм мәктәп компоненты буларак, гуманитар профильдәге классларда |
| **Инновациянең әһәмияте(вариантның астына сызарга)** | Республика күләмендәге әһәмияте, муниципаль дәрәҗәдәге әһәмияте, шәхси дәрәҗәдәге әһәмияте |
| **Инновациянең үсеш этабы (стадиясе)** | Реальләштерү этабы |
| **Ирешелгән нәтиҗә** | Программа гуманитар юнәлешле укучыларның |

| | |
|---|---|
| | милли үзаңы формалашу өлкәсендәге танып белү эшчәнлекләрен тирәнәйтү функциясенә ия булган “Тел” курсына өстәмә; сөйләм телен үстерүдә нигез; туган тел һәм әдәбияты укытучыларына һәм тәрбия өлкәсендә эшләүче класс җитәкчеләренә түгәрәк эш планы буларак тәкъдим ителергә мөмкин булган тәмамланган эш. |
| **Белем бирү системасының структур элементларына мөнәсәбәтле рәвештә инновациянең тибы** | Максат, бурычлар, яңалыгы; белем бирүнең эчтәлеге, тәрбия бирү, идарә итү; формаларда, методларда, алымнарда, чараларда яңалык, белем һәм тәрбия бирү технологияләре өлкәсендә; диагностика өлкәсендә. Контроль. Нәтиҗәләр бәясендә һ.б. |
| **Укучының шәхес булып формалашуга мөнәсәбәтле** | Шәһәр шартларында укыту-тәрбия процессында күп укучылар өчен шактый авыр тоелган сөйләм культурасын формалаштыруны, үз сөйләмен төзеп, логик эзлеклелектә, аңлаешлы итеп формалаштырып әйтә белүне, татар тарихы, мәдәнияте, сәнгате белән танышу максат итеп куелган. |
| **Куллану өлкәсе буенча** | Укыту процессында, тәрбия өлкәсендә, укучыларның мөстәкыйль, эшчәнлекләрен оештыру өлкәсендә |
| **Педагогик процесста катнашучыларның үзара мөнәсәбәт типлары буенча** | Коллектив укыту системасында |

Сөйләм, аралашу осталыгы һәрбер һөнәр вәкиле өчен мөһим. Кызганычка каршы, хәзерге көндә сөйләм осталыгына өйрәтү өчен дәресләрдә бирелгән вакыт кына җитми. Нәтиҗәдә, соңгы вакытларда без укучыларның хаталы сөйләмен, басым кую кагыйдәләренең сакланмавын, авазлар орфоэпиясе бозылышын, сөйләм ярлылыгын еш ишетәбез. Бүгенге көндә бу исә актуаль

проблема, шуңа күрә “Аралашу этикеты” түгәрәгенең эшчәнлеге бик мөһим. Программага түбәндәге максатлар куелган: укучыларга сөйләм әдәбенең нәтиҗәле алымнарын, аралашу үзенчәлекләрен, аралашу этикетын аңлату; сөйләмнең телдән һәм язмача формалары белән таныштыру, укучыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү; укучыларда аралашу культурасы тәрбияләү. Түгәрәк эшчәнлеге лекция, практикум, проект эше яклау, очрашу-әңгәмә, экскурсия, кичә һ.б. формаларында үткәрелү планлаштырыла, бу исә укучыларның төрле типтагы эшчәнлек формаларын үзләштерүләрен булдырачак.

Фәтхетдинова Рузилә Ринат кызы төзегән “Аралашу этикеты” авторлык программасы 5-11 сыйныф укучылары өчен укыту-методик комплексларына куела торган төп таләпләргә туры килә һәм аны уку-укыту эшчәнлегенә кертергә мөмкин.

Рецензент
Гыйләҗева Лилия Гыйльметдиновна,
ТР МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы
доценты, филология фәннәре кандидаты

05.02.2024

Подпись Гилязовой Л.Г. заверяю:

СЕКРЕТАРЬ РУКОВОДИТЕЛЯ ГАОУ ДПО
ИРО РТ Л.В. ХУСНУЛЛИНА